ШКОЛЬНАЯ ГАЗЕТА «ИКӘН»
МБОУ «ЕСТЕСТВЕННО-НАУЧНЫЙ ЛИЦЕЙ№ 95»
*КАЗАН ШӘҺӘРЕ СОВЕТ РАЙОНЫ "95 НЧЕ ЛИЦЕЙ"*

# IКӘН

Выпуск №6 (январь 2026)



Белый снег, пушистый
В воздухе кружится…
И. Суриков

***Сегодня в выпуске:***

*Зимние забавы* ***-стр.1***
*Январь–* ***стр.2***
*События месяца****-стр.3***
*Блокадный Ленинград-* ***стр. 4-5***
*Проба пера* **-стр.6**
*Учитель* года***-стр.7***
*Поздравляем****-стр.8***

***Мәктәбебез тормышы, анда булган яңалыкларга битараф булмаганнар өчен, безнең гәҗитебез кызыклы һәм кирәкле булыр, дип ышанабыз.***

***Гәҗитебезгә язмаларыгызны бастырырга теләсәгез, безгә аларны алып килә аласыз. Без язмаларыгызны бастырып чыгарып, сезгә җиткерербез.***

***Без ай саен сезне гәҗитебезнең яңа саннары белән шатландырырга әзер!( Кабинетыбызның номеры:313/333)***

## Зимние забавы

Зима — время, когда природа украшена белым покрывалом, а вокруг царит особая атмосфера волшебства. Но самое главное — это возможность весело провести время и насладиться зимними развлечениями!

Катание на санках и лыжах — классика зимних забав. Это не только увлекательно, но и полезно для здоровья, укрепляет мышцы и развивает координацию. Многие дети и взрослые с нетерпением ждут морозного утра, чтобы отправиться на горку или в лес на лыжную прогулку.

Конкурсы и игры на свежем воздухе тоже популярны зимой. Можно устроить снежные бои, лепить снеговиков или устраивать конкурс на самого креативного снегового ангела. А весёлый смех и хорошее настроение гарантированы!

Катание на коньках — еще один замечательный зимний вид развлечений. На катках и в хоккейных коробках каждый может почувствовать себя настоящим спортсменом или просто насладиться скольжением по льду.

Зимние забавы — это отличная возможность проводить время активно и весело, а также укреплять дружеские связи и получать новые яркие впечатления.

Так что, надевайте теплые вещи и не упускайте шанс сделать эту зиму незабываемой! Пусть забавы на свежем воздухе принесут радость и заряд бодрости вам и вашим друзьям.

# Январь — хрустальная дверь в Новый год



**Гыйнвар –** елның иң салкын ае, кыш түбәсе. «Җылы гыйнвардан Аллаһ сакласын», – дигәннәр. Бу аңлашыла да, җылы һәм кар әз икән, димәк, мул уңыш көтмә. Әмма салкын гыйнварлар рәттән кабатланмый. Әгәр бу ай узган ел җылы булган икән, быел суык киләчәк. Гыйнварда якты көн 1,5 сәгатькә озыная.

- Чәүкә һәм каргалар һавада очып әйләнсә – кар явар, карга утырсалар – җылыга, агачларның өске өлешенә кунсалар – каты суыкларга;
- Чыпчыклар чыркылдашса – җепшетә;
- Гыйнварда тукран шакылдата башласа – яз вакытыннан алда килә;
- Елның беренче ае җылы икән, яз соңара һәм май суык була;
- Ел башы суык булса, җәй эссе килә;
- Гыйнвар кар-буранлы булса, җәй көне яңгыр еш явар;
- Гыйнварның икенче яртысында кояшлы көннәр – яхшы уңышка;
- Гыйнварда озын һәм еш урнашкан боз сөңгеләре эленеп торса, уңыш яхшы булыр;
- Сукыр тычкан гыйнварда оясыннан чыкса – май салкын була;
- Гыйнварда март булса, мартта гыйнвардан курык.

**Яшәсен каникуллар!**

**Балаларның кышкы каникуллары тәмамланды. Укучылар ял итеп, көч җыеп тагын белем алырга мәктәпләргә ашыкты. Бу каникулны кем ничек үткәргән, әйдәгез, укучыларның үзләреннән сорап карыйк.**

**Фатыхова Альбина:**

Мин каникулларны бик күңелле һәм файдалы үткәрдем. Без гаилә белән башкалабыз Казан музейларына бардык. Анда без ретро машиналар күргәзмәсендә булдык, алар янәшәсендә фотога төштек. Аннары танылган рәссамның картиналарын карадык. Каникулда БДИга әзерләнүне дәвам иттем, дуслар белән аралаштым, саф һавада йөрдем.

**Габдуллина Әминә:**

Мин дә каникулларымны рәхәтләнеп ял да иттем, укуны да онытмадым. Гаиләм белән киногa бардык, дуслар белән аралаштым. Ид истә калганы Мөслимгә кунакка бару булды. Әбиемә, әниемә булыштым. Алда иң зур эш булып торган БДИ һәм олимпиадага әзерләндем.

**Хәмидуллин Тимур:**

Кышкы каникулларны мин бик күңелле һәм дуслар компаниясендә үткәрдем. Рәхәтләнеп ял иттек. Без көн саен саф һавада йөрдек, боз тауларында шудык чыршы мәйданчыкларында булдык. Бу каникуллар минем хәтердә әле озак сакланачак.

**Сафин Марат:**

Каникулларым бик шәп узды, гаиләбез белән тимераякта шуарга чыктык, матур атларда йөрдек. Ял да иттек, күңел ачу чараларында да булдык. Әлбәттә, уку турында да онытмадым. Дәресләргә әзерләндем, укырга көч җыйдым.

# События месяца

### «Җан авазы» шәһәркүләм поэмалар бәйгесе



23 нче гыйнвар көнне мәктәбебездә поэмаларны сәхнәләштерүнең шәһәркүләм 3 нче этабы булып узды.

"Хыял" театр коллективы Фатих Кәримнең "Кыңгыраулы яшел гармун" поэмасын сәхнәләштереп күрсәтте. Осталыкта, югары дәрәҗәдә сәхнә остасы итеп күрсәттеләр алар үзләрен.



Хөрмәтле "Хыял" театр коллективын 3 нче урынны яулаулары белән котлыйбыз! Баш өстендә аяз һәм тыныч күк йөзе, игелек телибез.




**Новогодний квиз в школе — праздник знаний и веселья!**

В январе в нашем лицее прошел яркий и увлекательный квиз, собравший учеников и учителей на веселую проверку знаний и командный дух. Мероприятие прошло в праздничной атмосфере с яркими декорациями, новогодней музыкой и теплым настроением.

Команды соревновались в различных конкурсах: от угадывания новогодних мультфильмов и загадок до викторин на тему зимних праздников и традиций. Участники показывали свои знания о новогодних обычаях разных стран и делились своими самыми яркими новогодними воспоминаниями.

Победителей ждала праздничная награда, а все участники получили заряд хорошего настроения и веру в чудо. Это мероприятие доказало, что Новый год — время веселья, дружбы и новых открытий!



Каждый понедельник наш лицей собирается на линейку — важное и традиционное мероприятие, которое сигнализирует о начале новой учебной недели. Во время линейки собираются все ученики и преподаватели, чтобы вместе начать неделю с хорошим настроением и информации.

На линейке обычно проходят короткие выступления директора, объявляются важные новости и планы на предстоящие дни. Также это хорошая возможность отметить достижения учеников, поздравить и вдохновить всех на новые успехи.

Это мероприятие помогает создать атмосферу единства, поднять настроение и задать позитивный настрой на учебную неделю. После линейки начинаются уроки, и все идут в класс с новыми силами.

**Ленинградның камалыштан чыккан көне**



1944 нче елның 27 гыйнвары - Ленинградның камалыштан чыккан көне. Бөек Ватан сугышы тарихындагы бөек вакыйгага 72 ел тулды. Ленинград 1941 елның 8 сентябреннән 1944 елның 27 гыйнварына кадәр - 872 көнгә камалышта кала. Анда яшәүчеләр өчен бу үлем исе аңкып торган иң авыр 872 көн була. Зур шәһәрләрне шулай озак саклауга мисаллар хәтта дөнья тарихында да юк. Шәһәрдә 2,5 миллион кеше кала. Ленинградның тиңдәшсез батырлыгы тарихка халыкның гаҗәеп кыюлыгы һәм геройлыгы эпопеясы булып кереп калды.

Камалышның беренче көннәреннән үк фашистлар шәһәрне вәхшиләрчә бомбага тота башлыйлар. Иң кыены - гаскәрләрне һәм шәһәр кешеләрен азык-төлек белән тәэмин итү. Булган запас тиз арада юкка чыга. 1941 елның 2 сентябреннән азык-төлеккә карточкалар кертелә. 1941 елның 25 декабреннән Ленинградта яшәүчеләр: эшләүчеләр - 350 грамм, хезмәткәр, балалар һәм кеше тәрбиясендә булучылар 200 грамм ипи ала башлыйлар. Ашау нормасы биш тапкыр киметелә. Кайгы һәр гаиләгә килә. Әти-әниләренең күз алдында уллары һәм кызлары үлә, балалар ятим кала. Күп гаиләләр тулысы белән үлеп бетәләр. Йортларда, урамнарда, кая карама - үле гәүдәләр, аларны хәтта җирләп тә өлгерә алмыйлар. Әмма бу ленинградлыларны тез чүктерә алмый.

Камалышта калганнарның ничек яшәвен сөйләп-аңлатып бирерлек кенә түгел. Мунчалар, кер юу урыннары эшләми, кибетләрдән бернинди кием-салым, хуҗалык товарлары табып булмый. Биналар сукыр лампа һәм чыра белән яктыртыла. Бераз җылы төшерү һәм су кайнату өчен өйдәге җиһазларны, китапларны ягалар. 1941 елның кышында завод һәм фабрикаларның күпчелеге ябыла. Оборонага кагылышлы, суднолар төзү, машина төзелеше предприятиеләре ябылмаса да, тулы көчкә эшли алмыйлар. Шундый шартларда ачлыктан хәлсезләнгән хезмәт ияләре салкын, караңгы цехларда өшегән һәм салкыннан яргаланып беткән куллары белән сугыш кирәк-яраклары ясыйлар. Өлкәннәр белән беррәттән, үсмерләр һәм балалар да тырышып эшли. Ачлык-ялангачлыкка карамастан, Ленинград галимнәре камалыштагы беренче кышта эшчеләр һәм инженер-техник хезмәткәрләр белән бергә фронтны сугыш кирәк-яраклары һәм кораллар белән өзлексез тәэмин итеп торалар.



Әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре чыгышлары белән ленинградлыларны рухи төшенкелеккә бирелүдән саклыйлар. Бу дәвердә радио искиткеч тәэсир итү көченә ия була. Ул шәһәр халкына кеше ышанмаслык кыенлыклар һәм интегүләргә түзәргә, көрәштә ялгыз булмауларын тоярга ярдәм итә.



Сугышка бәйле авырлыкларга, илдә азык-төлек җитмәүгә карамастан, Ленинград ягына он, май, ярма, шикәр һәм башка азык-төлек төягән эшелоннар өзлексез җибәрелә. Камалыштагы шәһәрне коткару өчен азык-төлек, корал бердәнбер юл - Ладога күле аша озатыла. Бу - боз каткан күл буйлап узучы данлыклы "Яшәү юлы". Шәһәрдән кешеләрне дә шушы юлдан алып чыгалар. Аннан 152 көн файдаланалар. Нәтиҗәдә йөз меңләгән ленинградлы ач үлемнән йолып калына. Беренче кыштан соң яз җитә. Ул беренчесенә караганда бераз җиңелрәк була. Шәһәр бирешми. Ул үзен геройларча яклый. Шәһәргә ил ярдәм итә.

Ленинград фронты гаскәрләре үзләренең сугышчан хәрәкәтләре белән бик күп немец гаскәрләрен үз якларына тарталар. Ленинградлыларның батырлыгы бөтен армиянең, бөтен совет халкының рухын күтәрә.

1944 нче елда Кызыл Армиянең гаять зур һөҗүмендә беренчесе Ленинград һәм Новгород янында немец-фашист гаскәрләрен тар-мар итү була. Һөҗүмнең кызулыгына дошман түзми. 1944 елның гыйнвар азагында Ленинград һәм Волхов фронтлары гаскәрләре кушыла. Дошман шәһәрдән 60-100 километрга читкә алып ыргытыла. Камалыш өзелә. 1944 елның 27 гыйнварында Ленинградны камалыштан тулысынча азат итү хөрмәтенә Нева ярларында 324 орудиедән тантаналы артиллерия салюты яңгырый.

Ленинград янында немец-фашист гаскәрләрен тар-мар итү - Бөек Ватан сугышы тарихында иң мөһим этапларның берсе.



Нежданная осень пришла в Ленинград,
Пожухлой листвой шелестит непогода,
И наша Нева вспоминает опять
Дождливый сентябрь сорок первого года.

Не те уже воды уносит река,
Блокадное время даво пролетело,
Но страшная надпись стучится в сердца,
Как память войны, как гроза артобстрела!

Их мало осталось - седых стариков,
Героев войны, рядовых обороны,
Прорвавших блокады стальное кольцо,
По Жизни - дороге, ведя эшелоны!

Редеют шеренги - мы помним о них,
Печален мотив уходящих мгновений...
И корочка хлеба, и детский отчаянный крик -
Пусть всё сохранится в сердцах поколений.

И стук метронома, и скрежет, и грохот вдали...
И город наш мирный, и Летнего сада ограда...
На всех языках, в лексиконах земли:
Война, Ленинград, сорок первый, блокада

# Проба пера

*Зимние каникулы -это прекрасная возможность насладиться зимой и яркими моментами. Каждый день наполняет ожиданием чуда.*

*Подготовка к Новому году стала началом наших праздников. Вместе с семьёй мы украшали дом, наполняли его волшебной атмосферой. Новый год я встретила за вечерним столом, чтобы разделить радость праздника с близкими и родными мне людьми.*

*После торжества мои каникулы стали еще интереснее. Первого января я посетила центральную ёлку около Кремля. Также была новогодняя ярмарка, полная сувениров, сладостей и игрушек. Улицы, украшенные гирляндами, создавали ощущение сказки.*

*В один из вечеров мы поехали кататься на коньках на Чёрное озеро. Было очень много людей, но это мне не помешало получить удовольствие от скольжения по льду. После активного катания мы с родителями решили согреться и зайти в уютное кафе неподалёку. Я заказала себе горячий шоколад и кусочек торта, Мы хорошо провели время и обменивались впечатлениями о катании.*

*На следующий день я пошла на горку с одноклассниками на ватрушках до самого вечера, громко смеялись и наслаждались каждой минутой. Такие моменты остаются в памяти навсегда. Веселье было незабываемым. Кроме того я успела на каникулах съездить и навестить бабушку. Она научила меня печь сладкие пирожки с разными начинками, и я теперь я могу порадовать ими своих близких. Я ходила в гости к родственникам и повидалась со своей сестрёнкой.*



*Эти каникулы подарили мне не только отдых, но и много полезных навыков. В следующем году я обязательно постараюсь сделать их более ярким.*

*Халимова Амиля, ученица 6 Л класса*

Вот зимняя пора настала,
Всё снегом белым заблистало.
Мороз крепчает, щиплет нос,
И ветер зимний песнь принёс.
Деревья в инее стоят,
Как будто в сказку нас манят.
Снежинки кружатся в танце нежном,
И мир вокруг становится безмятежным.
На санках с горки мы летим,
От смеха звонкого кричим.
Зима – волшебное время года,
Когда душа полна свободы!



*Нурмухамедова Эмилия, ученица 1 к класса*

# *Учитель года 2026*



В Казани проходит городской этап Всероссийского конкурса «Учитель года 2026»
На базе лицея №83 и №186 прошли две номинации: «Учитель - предметник» и «**Педагогический дебют**». В них приняли участие 20 учителей.
Конкурсантам предстоит продемонстрировать свои навыки в рамках четырех испытаний: урок, мастер-класс, блицтурнир и педагогическое интервью.



Учитель английского языка нашего лицея Салабайкина Татьяна Германовна продемонстрировала своё мастерство, показав членам жюри открытый урок и его самоанализ, педагогическое интервью и мастер-класс. Татьяна Германовна вошла в четверку сильнейших молодых педагогов города и выступила а блиц турнире в финале конкурса.



В Республике Татарстан стартовал конкурс профессионального мастерства **«Педагог-психолог 2026».**
22-23 января в городе Казани на базе средней общеобразовательной школы 31



Ново-Савиновского района состоялся городской этап. Членам жюри, в которое вошли ученые и практики педагогики и психологии (от Центра «Росток» педагог-психолог Альфия Закирова) предстояло оценить конкурсантов по трём испытаниям «Мастер-класс», «Профессиональный кейс», «Блиц-интервью». Высокий профессионализм, яркость мастер-классов, актуальность выбранных тем, практико- ориентированность были высоко оценены членами жюри.
Педагог-психолог нашего лицея Галимзянова Регина Рамильевна справилась со всеми заданиями и достойно представила район на городском этапе.



По итогам двух дней конкурсных испытаний определены победители, которые представят город Казань на республиканском этапе конкурса.

## Поздравляем

*Зарипова Инна Владимировна, учитель начальных классов (2 января)*
*Камалиева Алсу Фуатовна, учитель начальных классов ( 2 января)*
*Бариева Зульфия Фанзиловна, учитель начальных классов ( 6 января)*
*Закирова Фирюза Азатовна, воспитатель ГПД (10 января)*
*Андреева Светлана Николаевна, учитель начальных классов ( 13 января)*
*Ризаева Эльмира Владимировна, педагог доп.образования ( 16 января)*
*Алиева Джессика Ниязимовна, учитель английского языка ( 19 января)*
*Галиева Гульназ Шамиловна, учитель татарского языка ( 23 января)*
*Салахова Лейсан Ирековна, учитель татарского языка (24 января)*
*Мухарлямова Зарина Рустемовна, учитель русского языка ( 26 января)*

Старый Новый Год - это удивительное явление, которое сохраняет свою популярность в России и других странах постсоветского пространства. Этот праздник, отмечаемый в ночь с 13 на 14 января, стал символом продолжения новогодних традиций и возможности встретить Новый год еще раз. Старый Новый Год уходит корнями в историю перехода с юлианского календаря на григорианский. В 1918 году Россия перешла на новый календарь, и разница между датами составила 13 дней. Таким образом, те, кто придерживается старого стиля, продолжают отмечать Новый год по юлианскому календарю. Как и в случае с обычным Новым годом, Старый Новый Год наполнен различными традициями. Люди собираются за праздничным столом, готовят традиционные блюда, такие как оливье, селедка под шубой и мандарины. Многие семьи также украшают елку и обмениваются подарками.



Одной из интересных традиций является загадывание желаний. Люди пишут свои мечты на бумажках и сжигают их, чтобы отправить свои желания в небесные дали. Также популярны различные гадания, которые помогают узнать, что ждет в будущем.

*Хабибуллина Айлана, ученица 6 И*

**Редакциянең адресы:**

Казан шәһәре,

Азат Аббасов, 15 нче йорт

Тел. 89050229576

**Тираж** – 10 экз.

**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**

Габдуллаҗанова Айсылу Фәрид кызы

Нурмухамедова Регина Викторовна

**Редколлегия әгъзалары:**
Агзамова Зиля, Ахметзянова Риана, Багманов Искандер, Габитова Диляра, Гизатуллин Аяз, Гильмутдинова Зарина, Замалутдинова Самира, Исламгараева Амина, Исмагилов Карим, Каюмова Амалия, Леонтьева Екатерина, Нугманова Амалия, Леонтьева Екатерина,Каюмова Амалия, Садыгов Тагир, Бадретдинова Амина, Фадеев Амир, Кукарская Маргарита, Хаертдинова Риана, Суворова Таисия, Зайцева Екатерина, Хабибуллина Айлана.